КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 апрель г.Казань № 277

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 май, 385 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1356 нчы; 2022 ел, 25 апрель, 393 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1468 нче; 2023 ел, 14 февраль, 143 нче; 2023 ел, 16 март, 260 нчы; 2023 ел, 15 декабрь, 1623 нче; 2024 ел, 11 март, 129 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 2024 елда Россия Федерациясендә чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 елның 29 декабрендәге 902 номерлы» сүзләрен «2024 елда Россия Федерациясендә чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасының бертип моделен гамәлгә ашыру турында» 2023 елның 27 декабрендәге 895 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләре турындагы нигезләмәнең 2 пунктындагы өченче – алтынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин